# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Әлмәт авыл җирлегенең Әлмәт авылы торак пунктында
2022 елда үзара салым кертү турында

**2021 елның 22 ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенең Әлмәт авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2022 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге Әлмәт авылы территориясендә I нче группа инвалидлардан, ялгыз өлкән кешеләрдән, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, көндезге бүлекләрдә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1) Әлмәт авылында шлагбаумнарны реконструкцияләү ( төзелеш, коелган материаллар сатып алу);
2) Әлмәт авылында буяулар, янгынга каршы инвентарь, триммерларга запас частьләр сатып алу;
3) Әлмәт авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (агымдагы ремонт һәм урамнарны яктырту);
4) Әлмәт авылында МТЗ 82.1 тракторына хезмәт күрсәтү (ягулык-майлау материаллары, өстәмә җиһазлар, запас частьләр сатып алу, машина йөртүче хезмәтенә түләү);
5) Әлмәт авылында Ленин урамы, Тукай урамы, Яшьләр урамы, Л. Рәхмәтуллин урамы буенча авыл эчендәге юлларны ремонтлау (материаллар сатып алу һәм ташу);
6) Әлмәт авылында массакүләм чаралар (өлкәннәр көне, Инвалидлар көне, 9 Май, «Сабантуй», юбилярларны һәм алдынгыларны хөрмәтләү, спорт чаралары) үткәрү өчен бүләкләр алу;

3. Әлеге карарны Әлмәт авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Әлмәт авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче Д.Ә.Газизов